СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар
№ 2-42 | от «29» апреля 2019 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советының " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вәкиленә (эш бирүчесенә) коммерциянеке булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә бер генә идарәче башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы" 2017 елның 25 августында кабул ителгән 2-24 нче санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2007 елның 2 мартында кабул ителгән «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы федераль закон, 2018 елның 3 августындагы 307 нче санлы «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен контрольдә тотуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вәкиленә (эш бирүчесенә) коммерциянеке булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә бер генә идарәче башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакындагы" 2017 елның 25 августында кабул ителгән 2-24 нче санлы карарына (20.11.2018 ел, 2-38 санлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вәкиленә (эш бирүчесенә) коммерциянеке булмаган оешмалар белән (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә бер генә идарәче башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яки аларның коллегиаль

идарә органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмә “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен Эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәте алу тәртибе турында яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү (алга таба – нигезләмә, муниципаль хезмәткәрләр) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнгән һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек милекчеләр ширкәте (алга таба-коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең бушлай катнашуы), әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә, муниципаль берәмлек идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш (гамәлгә куючы (акционер) муниципаль берәмлек булган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль милектә булган оешмалар яки идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен (устав капиталында катнашу өлешләре) гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә алынган; федераль законнарда каралган башка очракларда».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(pravo.tatarstan.ru). игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкарып торучы Ф.Р.Дөлмиевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкарып торучы /Ф.Р.Дөлмиев/